СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

25 июль, 1998 ел. ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 84 (8241) | Бәясе билгеләнгәнчә

## АВЫР ЕЛНЫҢ ТӘҮГЕ ИКМӘГЕ

**Нурлат элеваторына тәүге яңа икмәкне кабул итү икенче зур тантана - ашлык киптерүне газга күчерү вакыйгасы белән туры килде.**

**- Ашлык киптерүне дизель ягулыгыннан газга күчерү безнең чыгымнарны 5 тапкырга кыскартачак,- дигән иде митинг алдыннан гына элеватор директоры Ә.Н.Миназов. - Ә бу - без эшкәртүчеләр өчен дә, җитештерүчеләргә дә зур файда.**



Беренче икмәк олауларын кабул итү дә шул рух тәэсирендә узды.

- Ниһаять, күптәннән килгән хыялыбыз тормышка ашты - икмәк киптерү, эшкәртүне газ белән башкару бәхетенә ирештек,- дип ачып җибәрде митингны элеватор директоры. Газчылар авыл эшчәннәренә уңайлык тудыру белән бергә, аларның беренче шатлыгын уртаклашырга да килгән булып чыктылар - митингның бер өлешендә Әхмәтнәкыйп Нурмиевич бу зур эшне башкарган алдынгы эшчеләргә бүләкләр тапшырды.

Хакимият башлыгы Ф.С. Сибагатуллин чыгышын шулай ук икмәк эшкәртүчеләргә гомерлек уңайлык бүләк иткән газчыларга рәхмәт сүзләре белән башлады, "Татхлебопродукт" холдинг компаниясе вице - президенты П.И.Кочкин да республика элеваторлары арасында икенче булып (беренчесе - буалылар) бу бәхеткә ирешкән нурлатлыларга уңышлар теләде. Әмма бу тойгы төп һәм изге тема - икмәк килү вакыйгасын икенче планга калдырды дип уйлау дөрес булмас иде. Әнә 5 хуҗалык - "Рассвет", "Кондырча", "Татарстан", Мичурин исемендәге, Хафизов исемендәге КХАлардан килгән беренче икмәк олаулары элеватор каршысында тезелгәннәр. Игенчеләрнең йөзе боеграк, кәефе төшенкерәк булса да (алар мондый гына уңыш көтмәгәннәр иде дә бит!) икмәк килү - ниндидер үзгә бер җылылык, тантана белән уза торган вакыйга ул.



- Быел икмәк уңышы белән мактана алмыйбыз. Әмма бу безнең гаеп түгел,- диде хакимият башлыгы игенчеләргә мөрәҗәгать итеп. - Шуңа булганын югалтуларсыз җыю, эшкәртү, табышлы урнаштыру - бүген төп бурыч булып кала. Шул ук фикерне Хафизов исемендәге КХА рәисе В.Ф.Булатов та куәтләде, игенчеләрнең сынатмаячагына ышандырды.

Беренчеләргә шартына китереп бүләкләр тапшырылды һәм менә "Рассвет" КХАсының тәүге машинасы ашлыктан анализга үрнәген алгыч астына басты.

Ак халатлы лаборантлар, кабул итү сезонын башлап, гәрәбәдәй бөртекләрне учларына алдылар. Бераздан аларның төгәл мәгълүматлары да әзер булды. Хафизов исемендәге, "Рассвет", "Кондырча" КХАларыннан 30 тонналап арыш китерелгән. Мичуринлылардан килгән уҗым бодаеның җилемсәлелеге 27 процент (!) тәшкил иткән! Дымлылыгы да сөенерлек - 14 процент. "Татарстан" бодае да җилемсәлелеге ягыннан әйбәт - 24 процент иде.

Ватан амбарларына беренче тонна икмәк салынды. Аз булса да, күп хезмәт кергән кадерле икмәк иде ул. Хәерле сәгатьтә булсын иде!

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**





**Рәсемнәрдә: Беренче олаулар; ашлыкның сыйфаты канәгатьләнерлек; "Рассвет" шоферы И.Төхфәтуллин; тәүге ашлыкны күпләр көтеп алды.**

**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

## ТАГЫН БЕР ҖИҢҮ БЕЛӘН



***Инде хәбәр иткәнебезчә, 19 июльдә Пятигорск шәһәрендә Русия Президенты дербие ярышлары үтте.***

Бу ярышларда безнең районнан Ледок һәм Эрожн юртаклары катнаштылар һәм бик әйбәт күрсәткечләр белән кайттылар.

Район хакимияте башлыгының Эрожн кушаматлы аргамагы, мәсәлән, Пятигорск шәһәре призына 3 яшьлек һәм аннан өлкәнрәк чиста токымлы атлар арасында 1200 метрга үткәрелгән бәйгедә беренче урынны яулады. Юртак бу араны 1.11.9 минутта (җайдагы - халыкара класслы жокей М.Казангаров) узды. Икенче аргамагыбыз, Татарстан Президенты үз иткән Ледок (җайдагы шул ук - М.Казангаров), танылган жокей, тренер Мурад Хәсән улы Балуров призына 2000 метрга ярышта 2.02.7 вакыт күрсәтеп, икенче урынны яулады.

Хәзер аргамаклар Казанда республика мөстәкыйльлеге көнендә үтәсе ярышларга әзерләнә.

## АЛАРНЫҢ ДА ҖАВАПЛЫ КӨННӘРЕ

***Урып - җыю вакыты игенче өчен генә түгел, башка һөнәр ияләренә дә үзенчәлекле чор ул. Әнә район мәдәният бүлеге каршында оештырылган махсус бригада өчен дә җаваплы көннәр башланды.***

Үзешчәннәребез үзләренең рухи байлыгын барлап, сәүдәгәрләр төрле товар төяп, чәчтарашлар һөнәри осталыклары белән сөендерү һәм даруханә хезмәткәрләре сәламәтлек ягыннан терәк булу өчен авыл хезмәтчәннәре янына юл тоттылар. Җыелма бригаданың беренче чыгышы "Сөлчә" игенчеләре тарафыннан якты йөз белән кабул ителде. Бу атнада бригада Чулпан, Бикүле, Салдакай якларына барып кайтуны планлаштыра. Игенченең көне якты, күңеле күтәренке булсын өчен тырышалар алар. Мондый эшчәнлек урып - җыю төгәлләнгәнче дәвам итәчәк.

***Балаларның җәйге ялы***

## ӨЧ СМЕНАДА

***Быел район хезмәт һәм мәшгульлек бюросы каршында оештырылган хезмәт биржасы аша мәктәп балалары җәйге каникулда эш белән тәэмин ителделәр.***

4нче мәктәптән ике сменада 14әр бала файдалы хезмәттә катнашты: мәктәпкә ремонт ясадылар, шефлары - "Нурлатнефть" НГДУсы объектларын тәртипкә китерүдә булыштылар.

Беренче августтан хезмәт лагеренең өченче сменасы башлана, анда да шул ук санда балалар эшләргә теләк белдерде инде.

## АКЧАЛАРНЫ АЛЫРГА ТИЕШЛӘР

**- Кызым, менә бу тиен акчаларны кибеттә алмадылар. Нишләп микән?**

Әбекәй учындагы сары акчаларны әйләндереп шулай сөйләнде. Алар арасында төрле елларда чыккан тиенлекләр: 1961нче елгысы да, 1993 елда чыкканы да бар иде.

Әбигә төгәл җавап бирәсебез бик килде. Шуңа да сорауны Нурлат исәп - хисап касса үзәге (РКЦ) начальнигы А.К.Сафиуллинага юлладык.

- Андый сорау белән өлкәннәр безгә дә еш киләләр, соравыгыз әйбәт булды әле,- диде Асия ханым һәм бу җәһәттән безгә тулы аңлатма бирде:

- Барлык кибетләр, сәүдә нокталары да СССР Дәүләт банкының 1961, 1991елгы үрнәктәге тәңкә акчаларын һәм Русия Банкының 1992, 1993 елгы үрнәктәге тиеннәрен бернинди тоткарлыксыз кабул итәргә тиешләр. Бу уңайдан РФ Президентының 4.08.1997 елда кабул иткән "Россия акча берәмлекләренең уртаклык бәясе һәм бәяләр масштабы үзгәрү турында"гы 822нче номерлы карары бар, һәм, шуннан чыгып, әлеге акчалар РФ территориясендә 1998 елның ахырына кадәр законлы түләү чарасы булып саналалар.

Әбекәй газетаны укырмы - юкмы , белмим, укыса да үз хокукын даулап йөрүчегә охшамаган. Аннан бигрәк прилавка артында торучылар бу сүзләрне берүк укый - аңлый күрсеннәр иде. Ул чагында үз белдекләре белән эш итеп, сатып алучыларның кәефен кыручылар бермә - бер кимер иде, дибез.

**С.НУРУЛЛИНА.**

## "УҢЫШ - 98" МАТБУГАТ ҮЗӘГЕ ХӘБӘР ИТӘ

Игенчеләребез, коры көннәрне кулдан ычкындырмыйча, уҗым культураларын тиз арада җыеп алуга бар көчләрен куялар. Хуҗалыклардагы механизаторларга МТСның җыелма отряды коллективы гаять зур булышлык күрсәтә. "Кейс" комбайннары Мичурин исемендәге, Кузнецов исемендәге, Синдряков исемендәге, "Киекле" хуҗалыкларында шактый нәтиҗәле эшләделәр, Муса Җәлил исемендәге һәм башка хуҗалыкларда да аларның эшеннән канәгатьләр.

Арыш һәм көзге бодайны иң күп мәйданнарда урып алучылар - алда санап үтелгән дүрт хуҗалык, шулай ук "Татарстан", Хафизов исемендәге ассоциацияләр. Урак колачлы барган хуҗалыклардан кузнецовлыларда уру белән сугу арасында да аерма юк диярлек. "Киекле", Синдряков исемендәге хуҗалыкларда да урылганның яртысыннан артыгы сuктырып алынган. Башкалар да уру белән сугу арасында зур аерма ясамаска тырышалар. Ә менә "Алга", "Үрнәк"тә, РСУ һәм сөт май комбинаты ярдәмче хуҗалыкларында, кичәге көнге мәгълүматларга караганда, уракка тотынмаганнар иде әле. Бер генә гектарда ашлык суктырмаган хуҗалыклар да бар.

Көзге чәчү өчен әзер мәйданнар - планлаштырылган кадәрнең өчтән бере тирәсе. Бу өч - дүрт көндә "Алга", "Киекле"дә 200әр, "Комбайн"да 370 гектар җир әзерләсәләр, "Сөлчә", "Родина", Синдряков исемендәге, "Заря", Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкларда әзер мәйданнар бер генә гектарга диярлек тә артмады.

Урак белән бергә терлек азыгы хәзерләү эше дә көн үзәгендә. Бу атнада сенаж салуда "Рассвет", "Киекле", "Кондырча", Синдряков исемендәге, "Таң", "Дуслык" хуҗалыкларында шактый нәтиҗәле эшләп алдылар - базларындагы яшел масса 200 -500әр тоннага ишәйде. Шул ук вакытта "Сөлчә"дә, Муса Җәлил исемендәге, "Алга", РСУ һәм "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыкларында бу көннәрдә сенаж запасы артмады диярлек. Район буенча сусыл азык 16 мең тоннадан күбрәк тупланды инде. Печән кирәк кадәрнең 40 процентына якын. Бу атнада ул эштә Мичурин исемендәге хуҗалык элеккечә үк өлгер булды: печәнне 500 тоннага якын ишәйтеп, аны еллык ихтыяҗның өчтән икесеннән күбрәк итеп куйды. Синдряков исемендәге, "Заветы Ильича", "Чирмешән", "Чулпан", "Таң" хуҗалыкларында да бу атнада печәнчеләр яхшы эшләде.

Кичәге көнгә бер шартлы терлеккә әзерләнгән иң күп азык берәмлеге "Кондырча"да - 12,4, "Заря"да -9,4, "Дуслык"та - 8,7 һәм Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкта - 7,2 центнер. Ә иң азы "Сөлчә"дә - 1,3 центнер гына.

## Әңгәмәдәш - хакимият башлыгы

***Нурлат районы ике ел элек кенә икътисади күрсәткечләре буенча республикадагы иң арттагы районнарның берсе - 37нче урындагысы иде. Моннан тыш, район авыл хуҗалыгы буенча 145 млрд., ә хезмәт хакы бирүдә 2,5 млрд. сум әҗәтле булды. Нурлатның уңдырышлы кара туфрагы (2/3 өлеше) мул уңыш белән куандырырга теләми, сыерлар да сөтне үтә саран бирде. Бер сүз белән әйткәндә, район 1994 елдан бирле зыянга эшләде, ягъни хөкүмәт акчасын кимерде. Һәм ул данлыклы шикәр заводы, эшкәртү, җитештерү предприятиеләре, нефть сәнәгате гөрләгән кара туфраклы Нурлат җирендә.***

***Нурлат районы һәм шәһәре хакимияте башлыгы итеп Татарстанның элекке авыл хуҗалыгы министры Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин билгеләнгәч, районда тылсымчы таягы уйнагандай, тыныч кына яшәгән кешеләр генә түгел, фермалар, хәтта җирләр дә дәррәү йокыдан уянып киткәндәй булды. Һәр гектар җирдән алынган иген уңышы кешегә әйтеп кеше ышанмастай биеклеккә күтәрелә - 46 центнердан узып китә, савым да икеләтә арта. Район узган ел 177,5 млрд. сумлык ашлык, сөт, шикәр сата. Нурлат табыш бирә торган районга әверелә. Уңыш авыл хуҗалыгындагы, сәнәгатьтәге зур үзгәртеп корулар, фән казанышларын кулланып эшләү, акча табу юлларын җентекләп өйрәнү, булганның бәрәкәтен белеп тоту аша килә.***

***Нурлат районы һәм шәһәр хакимияте башлыгы Фатих әфәнде Сибагатуллинга беренче соравым да менә шул үзгәртеп корулар турында булды.***

# ФАТИХ СИБАГАТУЛЛИН:
# «МИН ЯРАКЛАША БЕЛМИМ...»

-Тормышта бер әйбер дә максатсыз эшләнергә тиеш түгел. Нинди генә эшкә алынсаң да, "Ул нигә кирәк, халыкка ни - нәрсә бирә?" дигән сорау кую мөһим. Уйлап карасаң, илдә хәтта корал җитештерү дә безнең тыныч тормышны тәэмин итү өчен бит. Революцион процессларның - игенчелектәме, терлекчелектәме, нефть чыгарудамы, эшкәртү тармагындамы - соңгы нәтиҗәсе финанслауда, икътисади күрсәткечләрдә чагылырга тиеш. Уйланып эшләнмәгән үзгәртеп корулар уңышсызлыкка китерергә мөмкин. Ә тарихта сабак алырдай вакыйгалар шактый. Париж коммунасын гына алыйк. Аның нәтиҗәсе канлы фаҗигагә китергән: йөз меңләп кеше атыла, каторгаларга озатыла, качып яшәргә мәҗбүр була...

Без районда үзгәртеп коруларга керешкәнче аның ахырын күзалларга, соңгы нәтиҗәләрен күрергә тырыштык, исәпләдек, төрле яклап уйладык. Авыл хуҗалыгында да, сәнәгатьтә дә акча китерердәй, табыш бирердәй нәтиҗәле, аз чыгымнар белән мул продукция җитештерү ягъни продукциянең үзкыйммәтен киметү юлларын эзләргә, шуңа йөз тотарга кирәк иде. Эшне программа булдырудан башлап җибәрдек. Соңгы нәтиҗәсе халыкның тормыш - көнкүреш дәрәҗәсен яхшырту булырга тиеш, дип тәгаенләнде.

Шушы көннәрдә Министрлар кабинетының киңәйтелгән утырышы булды. Ул безнең дөрес юнәлештә икәнлегебезне күрсәтте. Утырышта продукцияне аз чыгымнар белән җитештерү турында ассызыклап әйтелде.

***- Фатих әфәнде, райондагы матур - күркәм үзгәрешләрне авыл хуҗалыклары кооперативлары ассоциацияләрендә йөргәндә шактый күрдек. Диңгездәй дулкынланып утырган иген кырларына, ишек аллары чия, карлыган бакчалары белән бизәлгән дуңгыз комплексларына карап сокландык. Мәһабәт мәчетләргә карап горурландык, яшьләр үзеген, спорт комплексларын күреп сөендек.***

-"Ни одним хлебом сыт человек", диләрме әле урыслар. Җитештерүнең үз - үзен аклавына, рентабельлелеккә ирешү белән беррәттән, халыкка рухи азык бирү, яшьләргә ял итәргә мөмкинлекләр булдыру, балаларга белем алырга заманча шартлар тудыру да бик кирәк. Әйтик, районга мин килгәч кенә ике мәчет, бер чиркәү (хәзер бездә барлыгы 27 мәчет, 3 чиркәү бар) салдырдык. Абый - апалар, өлкәннәр аны сөенеп, рәхмәт әйтә - әйтә кабул иттеләр, шатлыкларыннан еладылар хәтта. Мәчетләр белән халкыбызга иман кайта дигән сүз бит бу. Әлегә яшьләрнең күбесе мәчеткә йөрмәсә дә, аларның балалары әби - бабайларының намаз укыганын күреп, моңлы азан тавышын ишетеп үсә.

Яшьләр үзәге салып кую да, бассейн булдыру, спорт комплексын башкалада яшәүчеләр көнләшерлек итеп яңарту да егет - кызларыбыз алтын кебек вакытларын, урамда килә сарып, шәләй - вәләй килеп, тәртипсезләнеп уздырмасыннар өчен бит. Башта яшьләргә ял итәргә мөмкинлекләр тудыр, аннары инде алардан таләп итәргә дә була.

Ун еллар элек кенә без искечә яшәргә ярамый, дидек, ә яңача көн күрү формасы юк иде. Шул вакытларда М.Горбачев әйткән бер сүз хәтеремдә калды: "То, что непротивозаконно, то законно". Ә законнар җитешми. Хәзер инде дистә еллардан килгән әхлаксызлыкны бетерергә, имансызларга иман китерергә кирәк.

***- Фатих Сәүбәнович, ветеринария фәннәре докторы хакимият башлыгы белән килешеп яшиме?***

- Фәннән башка, гади генә итеп әйтсәк, бүгенге тормыш бара да алмый. Миңа кооператив хуҗалыкларда сез күреп, танышып кайткан үзгәртеп коруларны эшләү бик җиңел. Менә хәзер Нурлатта авыл хуҗалыгы академиясенең филиалын ачарга әзерләнәбез, чөнки бүген үзгәртеп кору программасын тормышка ашыру, мул уңыш үстерү һәм ит - сөт җитештерү хуҗалык рәисләренең белемле булуын таләп итә. Кайвакыт урта белемле җитәкчеләр белән гәпләшкәндә ике телдә сөйләшкәндәй буласың. Һәм мин барлык хакимият башлыкларының да фән докторы булуын теләр идем.

***- Фән бит шактый чыгым да таләп итәргә мөмкин. Ә бүгенге көндә акчага кытлык кичермәгән берәр район, хуҗалык бармы икән?..***

- Яхшы әйбер беркайчан да арзан тормый. Арзан дип чөгендерне кул белән эшкәртеп карыйк инде. Ул, киресенчә, кыйммәтрәккә төшә. Саран ике тапкыр түли, диләр бит. Шулай килеп чыга да инде ул. Кесәне капшый башлагач, яхшы кием дә отышлы түгел кебек. Затлысы кыйммәт дип, бер кеше дә киндер күлмәк киеп йөрми. Югыйсә аны ел буе кисәң дә, туздыра алмыйсың...

***- Фатих әфәнде, сез Балтачта, Яшел Үзәндә эшләгәнсез, Мамадышта КПСС район комитетының беренче секретаре булдыгыз (ул елларда Мамадыш районында икътисади күрсәткечләр нык күтәрелеп киткән иде). Хәзер Нурлат... Һәр төбәк халкының бер үзенчәлеге була. Нурлат халкы нинди сыйфатларга ия? Бәлки инде үзегез дә аларга яраклашып, җайлашып беткәнсездер?***

- Мин яраклаша белмим. Ә халык турында болай әйтер идем: башкаларга бәя биргәнче, башта үзеңә читтән карарга кирәк. Әгәр дә халык тырышмаса, эшләмәсә, район алга барыр идемени?..

Миңа һәрвакыт, кайда гына эшләсәм дә, әйбәт кешеләр туры килде. Министр булганда да. Мин андый кешеләргә гомерем буе рәхмәтлемен. Нурлат халкы белән дә беренче көннәрдән үк аңлашып, иңгә - иң торып эшлибез. Дөрес, һәр төбәкнең үзенә генә хас үзенчәлекләре була. Шуларга бәйле рәвештә кайчак эшне оештыруда кыенлыклары да килеп чыга. Әйтик, Мамадышта эшләгәндә тимер юл булмавы шактый аяк чалды. Анда күбесенчә татарлар яши, милләт төрлелеге юк иде диярлек. Ә Нурлатта татарлар, урыслар, чувашлар кулга - кул тотынып гомер итәләр. Бирердә яшәгән 57140 кешенең 55,8 проценты урысча сөйләшә. Төрле халык, төрле гореф - гадәт. Бу яктан караганда, биредә, Мамадыш белән чагыштырганда, катлаулырак. Аннары һәр халыкның үз асыл затлары, үз әтрәк - әләмнәре була. Ул милләткә дә, төбәккә дә карамый.

***- Сез гомерегез буе җитәкче булып эшләгән кеше. Ул нинди булырга тиеш?***

-Кешедә җитәкче сыйфатларының 40 проценты туганда ук булырга тиеш. Әти - әниеңнән бирелмәсә, башкача керми. Җитәкче, иң беренче чиратта, коллективны яратырга, үзе белән янәшә эшләгән кешеләрне хөрмәт итәргә, үз кулы астында эшләүчеләр турында, болар минем туйдыручыларым, алар аркасында мин күкрәк киереп йөрим, эшлим, дип уйларга тиеш.

***-Фатих әфәнде, сез нинди кешеләр белән эшләргә яратасыз?***

- Эшчән, булдыклы кешеләрне яратам. Тел тегермәнен тартып кына мул тормыш корып булмый. Ялганга түзеп тора алмыйм. Хыянәтне кичермим. Гадел кешеләрне хөрмәт итәм. Һәр кеше дә үз кимчелеген үзе күрергә, үзе төзәтергә тиеш.

***- Һәр малай нинди булса да хыял белән яши, нәрсә белән булса да мавыга. Ә менә нәни Фатихка нәрсә җене кагылган иде?***

- Атларны, терлекләрне бик ярата идем, буш вакытымда һаман маллар янында булдым. Алар авырганда кызгана, үземчә дәвалый да идем. Ветеринария институтына укырга керүемә дә шушы хирыслыгым сәбәпче булгандыр. Аннары күңелемнең иң түрендә бер кешегә дә әйтми торган олы бер хыялым бар иде: халыкның хөрмәтле кешесе буласым килде.

Хәзер дә бик арыган вакытларымда, күңел төшкән сәгатьләрдә атлар янына барам, аларны шикәр белән сыйлыйм, ялларыннан сыйпыйм, кешнәүләре әллә нинди күңелсез уйларны, киеренкелекне юкка чыгара, йөрәк җиңеләеп кала. Ял туздырып чапкан аттан да матуррак күренеш юк дөньяда.

***- Гаиләдә мин сезнең биш туган үсүегезне, барыгызның да югары белем алып, мәртәбәле урыннарда эшләвегезне беләм. Әти - әниегезгә биш баланы югары уку йортында укыту авырга туры килмәдеме икән?***

- Мин гаиләдә икенче бала идем. Әти бик булдыклы, эшчән кеше. Безне дә алны - ялны белми эшләргә, тынгысыз булырга ул өйрәтте. Терлекләрне күп асрый идек. Әтиебез аркасында юклыкта, хәсрәт тә күрмәдек.

***- Әйтик, сезгә яки районга күп кенә миллиардлар акча бирделәр ди. Сез аны нәрсәгә тотар идегез?***

- Балалар, инвалидлар, өлкәннәр ихтыяҗына, аларның саулыгын ныгытуга, яшьләргә белем бирергә, аларның иманга кайтуына булышуга, җинаятьчелекне киметүгә китерә торган чараларга тотар идем. Кайбер гаиләләрдә балаларның кимсенеп, мохтаҗлыкта үсүләре, өлкәннәргә тиешле хөрмәт күрсәтелеп җитмәве, җинаятьчелек, авыру балаларның артуы - бу мәсьәләләр мине бик борчый.

***- Фатих әфәнде, Нурлатка сез хакимият башлыгы булып килгәч, район гел телдән төшми: һаман биредәге яңалыкларны, матур үзгәрешләрне сөйлиләр.***

- Районны мин түгел, халык күтәрә. Бергәләп эшлибез, бергәләп ял итәбез!

**(Әңгәмәдәш - Сөембикә КАШАПОВА.)**

# МӘХӘББӘТЕ ИЛӘ МӘШӘКАТЕ

*Районда Югары Нурлаттан да мәһабәтрәк, гүзәлрәк авыл бармы икән? Капка төпләренә яшел чирәмнән келәм җәелгән йортлар, каралты - кура төзек, матур. Бу авылны үзе бер нәни Швейцария диярга булыр иде. Биредә авыл көнкүрешенең барлык проблемалары хәл итеп бетерелгән: йортлар, социаль - көнкүреш, производство биналары газлаштырылган, суны краннан гына агызасы, электр челтәре яңартылган, урамнар буйлап асфальт юл уза. "Кондырча" авыл хуҗалыгы кооперативына кергән бу авылда сыерлар да сөтне тәүлегенә ике чиләктән артык - 24шәр литр бирәләр. Бу хуҗалык уңганнары узган ел чәчүлек җирнең һәр гектарыннан 64 центнер икмәк җыеп алганнар.*

*- Болар барысы да хуҗалык рәисе Йосыф Галиулла улы Әхмәтсафинның булдыклылыгыннан килә,- ди хакимият аппараты җитәкчесе Флера Ногъманова.- Авылдагы терлекчелек, хуҗалык каралтылары тирәсендәге тәртипне, чисталыкны гына күрегез сез.*

*Билгеле, район җитәкчеләре Йосыф Галиулловичка тынычлап калырга ирек бирмәгәннәр, хуҗалыкка янәшәдәге икътисади күрсәткечләре, социаль хәле белән дә шактый арттагы Түбән Нурлат авылын да китереп кушканнар. Уңганнан эш тә курка, диләр бит, Йосыф Әхмәтсафин кулына эләккән Түбән Нурлатның да гөл кебек ямьләнүенә өмет зур.*

*Ләкин "Кондырча" авыл хуҗалыгы кооперативының даны эшләнгән эшләрендә генә түгел. Биредә затлы, ыспай гәүдәле, карап туйгысыз матур нәселле 51 ат бар. Татарстан, хәтта Русия күләмендә бәйге тотып приз яулаган атлар.*

*- Атлар фермасының оешуына 10 еллар бар инде,- дип сөйли Йосыф Әхмәтсафин,- Пятигорскидан, Калмык республикасыннан нәселле атлар алып кайттым. Атлар заводы ясатасым килгән иде.*

*Район хакимияте башлыгы булып Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин килгәч, бу эшкә юл ачылып китә. Нефтьчеләр ярдәме белән бер иске бинаны ат абзары итеп үзгәртеп коралар. Ниятләре - ферманы ат заводы итеп үстереп, нәселле атлар үрчетеп, башка районнарга да сату.*

*- Атларыбыз колынлый. Киләсе елда аларның саны 61гә җитәчәк,- диләр биредә эшләүчеләр.*

*Рәиснең сүзләренә караганда, хуҗалыкта сыер, сарык, мөгезле эре терлек асрау, продукция җитештерү, вак эшле, сабый бала кебек тәрбия сорый торган аксөяк атлар тоту белән чагыштырганда, берни түгел икән. Ләкин мәхәббәте белән мәшәкате дигәндәй, яраткач түзәсең.*

*Ә аксөяк атларга, дөрестән дә, яхшы тәрбия кирәк. Аларны махсус шампуньнар белән юу, бал, кукуруз, солы, ботка кебек ризыклар белән сыйлап тору, көн дә күнегүләр үткәрү - болар көндәлек мәшәкатьләр.*

*- Чабышкы атлар тәрбиялләгәндә тагын бик тә авыр бер мәсьәлә бар,- дип сүзен дәвам итә Йосыф әфәнде. - Профессор кирәк икән, аны табу берни түгел. Ә менә жокей...*

*Үзе дә кечкенәдән үк ат менеп чабарга яраткан Й.Әхмәтсафин үз улын да шушы эшкә тарткан.*

*Атлар яраткан - игелекле булган, диләр бит. Югары Нурлатта да игелекле кешеләр яши һәм матур итеп яши.*

***("Мәдәни җомга"дан).***

# телепрограмма




## ПОНЕДЕЛЬНИК

### 27 ИЮЛЯ

**«ТАТАРСТАН»**

7.00 -8.00 "Чулпан"
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 Прямая связь
19.45,21.45 Новости
20.00 "Я, наверное, влюблюсь..."
20.25 "Тамчы"
21.00 "Вечный зов"

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 1.15 Новости.
9.15,18.20"Роксолана-пленница султана". Сериал.
10.00 Поле чудес.
10.55 Здоровье.
11.30 19.30 Угадай мелодию.
12.15 "Вместе".
13.00 "Змеелов". Х/ф.
15.20 Мультсериал.
15.45 Марафон -15.
16.05 Звездный час.
16.40 Сериал "Лето наших надежд".
17.10"...До 16 и старше".
17.30 "Вокруг света".
19.05 Час пик.
20.00"Человек в маске".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.35 Сериал "Горец".
22.45 Серебряный шар
23.30 Х/ф "Преднамеренное убийство".

**РОССИЯ**

7.00 8.45 15.40Мультфильм.
7.15 Проснись.
7.30 11.00 14.00 17.00 20.30 23.40 Вести.
8.00 0.00"Дежурная часть".
8.20 "Рецепты".
8.30 Деньги.
9.10 "Православный календарь".
9.15 "Аншлаг" и Ко.
10.10,20.35"Санта-Барбара".
11.30 Дневник фестиваля искусств.
11.40 "Театр + TV".
12.20 Х/ф"Вечный зов"
13.30 "У всех на устах"
14.30"Отпуск в сентябре".1 серия.
16.00 Башня.
16.30"Первые поцелуи".
17.30 Автоспорт.
21.35 Конкурс молодых исполнителей.
0.10 Сиреневый туман.
0.50 Автошоу.

**РИО**

17.00 Диск-канал.
17.30 0.10 ТСН-6.
17.35 0.15Дорожный патруль.
17.50 Видеоклипы.
18.00 Те Кто.
18.50"Дежурная аптека"
19.30 20.30 21.50 22.40 Новости
19.30 Ток-шоу.
20.55 "Тайны отца Даулинга"
21.55Театральный понедельник.
22.45 Кинотеатр ТВ-6.
0.30 ДИСК - канал.

## ВТОРНИК

### 28 ИЮЛЯ

**«ТАТАРСТАН»**

7.00-8.00 "Чулпан"
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 "Диалоги с..."
19.30 Ял концерты
19.45,21.45 Новости
20.00"Телебез сагында"
20.30"Әлли- бәлли -бәү"
21.00 "Вечный зов"
22.00"БКЗ приглашает..."
22.15 "Бизнес ТВ"

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.05 Новости.
9.15,18.20"Роксолана-пленница султана ".
10.00 "Человек в маске".
10.45 Смехопанорама.
11.20 Домашняя библиотека.
11.30 19.30 Угадай мелодию.
12.15 "Вместе".
13.00"Приключения королевского стрелка Шарпа".
15.20 Мультсериал.
15.55 Счастливый случай.
16.40 Сериал "Лето наших надежд".
17.10 "...До 16 и старше".
17.30 "Вокруг света".
19.05 Час пик.
20.00 "Тема".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.35 Х/ф "Его звали Роберт".
23.20 Док.детектив.

**РОССИЯ**

7.00 8.45 15.45 Мультфильм.
7.15 Проснись.
7.30 11.00 14.00 17.00 20.00 23.45 Вести.
8.00,0.05"Дежурная часть".
8.20 "Стронг" представляет.
8.30 Деньги.
9.05 "Православный календарь".
9.10 Диалоги о животных.
10.05 20.35"Санта-Барбара".
11.30 12.22"К-2"представляет
14.30"Отпуск в сентябре". 2 серия.
16.00 Башня .
16.30 "Первые поцелуи"
17.55 Кроссворд.
22.35Т/с "Пси фактор".
22.25 0.20 Конкурс молодых исполнителей.
1.15 Звуковая дорожка.

**РИО**

17.05 ДИСК-канал.
17.30 23.50ТСН-6.
17.35 Дорожный патруль
17.50 Видеоклипы.
18.00 Те Кто.
18.50 "Дежурная аптека"
19.30 20.30 21.50Новости.
19.30 Мужской клуб.
20.55 "Тайны отца Даулинга"
21.55 Х/ф "Стрекоза".
0.00 Дорожный патруль.
0.15 ДИСК-канал.
1.00 "Знак качества".
1.15 Х/ф "Бесстрашный тигр"(США).

## СРЕДА

### 29 ИЮЛЯ

**«ТАТАРСТАН»**

7.00-8.00 "Чулпан"
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00"Сельские будни"
19.15 Ания Туишева концерты
19.45,21.45 Новости
20.00 "Карт - бланш"
20.30"Әлли-бәлли-бәү"
21.00 "Вечный зов"
22.00 "Точка опоры"

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.25 Новости.
9.15,18.20"Роксолана-пленница султана".
10.00 Тема.
10.45 В мире животных
11.30 Джентльмен-шоу.
12.15 "Вместе".
13.00 Т/с "Приключения королевского стрелка Шарпа".
14.15 Серебряный шар.
15.20 "Тин-Тин идет по следу".
15.45 "Классная компания".
16.15 Зов джунглей.
16.40 "Лето наших надежд".
17.10"...До 16 и старше"
17.30 "Вокруг света".
19.00 Футбол.
19.50 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.35 Х/ф "С тобой и без тебя".
23.20 Баскетбол.

**РОССИЯ**

7.00 8.45 15.45 Мультфильм.
7.15 Проснись.
7.30 11.00 14.00 17.00 20.00 23.45 Вести.
8.00 0.45"Дежурная часть".
8.20 "Стронг"представляет.
8.30 Деньги.
9.05 Православный календарь.
9.10 Маски-шоу.
9.35 Подиум д"Арт.
10.05 20.35 "Санта-Барбара".
11.30 Моя семья.
12.25 "Вечный зов".
13.45 Ваши любимые мелодии.
14.35 "Зеркало для героя". 1 серия.
15.45 Мультфильм.
16.00 Башня.
16.30"Первые поцелуи"
22.35 "Агата Кристи. Пуаро". Телесериал.
22.35 0.20 "Песни лета".
1.25 Дневник фестиваля искусств.
1.35 Живая коллекция.

**РИО**

17.05 ДИСК-канал.
17.30 23.55 ТСН-6.
17.35 Дорожный патруль.
17.50 Видеоклипы.
18.00 Те Кто.
18.50Дежурная аптека
19.30,20.30 21.55 Новости.
19.30 Ток - шоу.
20.50 "Тайны отца Даулинга"
21.55 Кинотеатр ТВ-6.
0.05 Дорожный патруль.
0.20 ДИСК-канал.
1.05 "Знак качества"
1.20 "Взрыв"Х/ф.

## ЧЕТВЕРГ

### 30 ИЮЛЯ

**«ТАТАРСТАН»**

7.00-8.00 "Чулпан"
18.25 "Банк "Заречье" информирует..."
18.45, 20.45 "Җиһан"
19.00 "Туй йолалары"
19.25 "Эхо голоса твоего"
19.45,21.45 Новости
20.00 ГАИ - информ
20.15 "Шигъри мизгелләр"
20.30"Әлли-бәлли - бәү"
21.00"Вечный зов"
22.00 "Клуб Бөлл"

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 1.00 Новости.
9.15,18.20"Роксолана-пленница султана".
10.00 Америка с М.Таратутой.
10.30 Пока все дома.
11.20 Домашняя библиотека.
11.25,19.30"Эти забавные животные".
12.15 "Вместе".
13.00 "Приключения королевского стрелка Шарпа".
14.05 23.55 Баскетбол.
15.20 Сериал "Невероятные приключения Джонни Квеста".
15.45 Классная компания.
16.15 Волшебный мир или Синема.
16.40 Сериал "Лето наших надежд".
17.10"...До 16 и старше".
17.30 "Вокруг света".
19.05 Час пик.
20.00 Человек и закон.
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.35 "Ураган". Х/ф.

**РОССИЯ**

7.00 8.40 15.45 Мультфильм.
7.15 Проснись.
7.30 11.00 14.00 17.00 20.00 23.45 Вести.
8.00,0.05"Дежурная часть".
8.20 "Мир здоровья".
8.30 Деньги.
9.05"Православный календарь".
9.10 Вовремя.
9.35 Сам себе режиссер
10.05,20.35"Санта-Барбара".
11.30 Совершенно секретно.
12.25 "Вечный зов".Х/Ф
13.30 Автошоу.
14.35 "Зеркало для героя". 2 серия.
16.00 Башня.
16.30 "Первые поцелуи".
17.30 Дневник фестиваля.
17.45 Кроссворд.
21.35 "Притворщик".Х/ф
22.25 0.20 Закрытие международного фестиваля искусств.
1.25 Подиум д"Арт.
1.55 Эротич. мелодрама "Презрение".

**РИО**

17.05 23.45 ДИСК-канал.
17.30 23.25 ТСН-6.
17.35 Дорожный патруль
17.50 Видеоклипы.
18.00 Те Кто.
18.55"Дежурная аптека"
19.30 20.30 20.50 Новости.
19.30 Ток-шоу.
20.55"Бесстрашный"Х/ф
23.35 Дорожный патруль.
0.30 "Знак качества"
0.50 "Безумный уикэнд девушек-болельщиц".

## ПЯТНИЦА

### 31 ИЮЛЯ

**«ТАТАРСТАН»**

7.00-8.00 "Чулпан"
18.45,2045 "Җиһан"
19.00 "Батулла дәресләре"
19.45,21.45 Новости
20.00"Музыкаль сәхифә"
20.30"Әлли-бәлли-бәү"
21.00"Җомга көн кич белән"
22.00 Наил Дунаевның иҗат кичәсе

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 23.55 Новости.
9.15,18.20 "Роксолана-пленница султана".
10.05 Клуб путешественников .
10.55 Смак.
11.15 Домашняя библиотека.
11.25 "Играй, гармонь любимая!"
12.15 "Вместе".
13.00 "Приключение королевского стрелка Шарпа".
13.50 Баскетбол.
15.20Сказка "Остров на крыше мира".
16.55 "Улица Сезам".
17.25 "Чердачок Фруттис".
19.10 Здоровье.
19.45 "Поле чудес".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.35 Х/ф "Настоящий друг".
23.35 Взгляд.
0.30 Баскетбол.
1.35 Х/ф "Японский городовой".

**РОССИЯ**

7.00 8.45 15.45 Мультфильм.
7.15 Проснись.
7.30 11.00 14.00 17.00 20.00 23.45 Вести.
8.00 0.35 "Дежурная часть".
8.20 "Мир здоровья".
8.30 Деньги.
9.10 "Православный календарь".
9.15 Док.фильм.
10.10,20.35"Санта-Барбара".
11.30"XX век. Майя Плисецкая и Пьер Карден. Мода и танец"
12.25 "Вечный зов".
13.35 Ваши любимые мелодии.
13.45 Торговый дом "Ле Монти".
14.30 Х/ф "Нежность"
16.00 Башня.
16.30"Первые поцелуи"
18.00 "Лабиринт".
21.35 Сам себе режиссер.
22.20 "Городок".
22.40 0.05 Х/ф "Багси Мэлоун"
0.50 Драма"Мисс Мэри"

**РИО**

17.05 ДИСК-канал.
17.30 ТСН-6.
17.35 Дорожный патруль.
17.50 Видеоклипы.
18.00 Те Кто.
18.50"Дежурная аптека"
19.25 20.30 Новости.
19.30 Катастрофы недели.
20.00 "Вы - очевидец".
20.55Х/ф "Крестоносец."
23.00 "Обоз".
0.00 "Такси ТВ-6".
0.15 ТСН-6.
0.15Дорожный патруль.
0.40 ДИСК-канал.
1.25 "Знак качества"
1.40 "Летняя горячка"(США).

## СУББОТА

### 1 АВГУСТА

**«ТАТАРСТАН»**

7.00-8.00 "Чулпан"
17.40 "Үги кыз"
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 "Бизнес ТВ"
19.45,21.45 Новости
20.30 "Зәлидә"
20.30"Әлли - бәлли - бәү"
20.45 "Музыка плюс"
21.15"Видеоспорт-авто"
21.45 "Точка опоры"
22.00 "Сөн буенда туган моңлы шагыйрь"

**ОРТ**

8.00Х/ф"Чертова дюжина."
9.30 16.50 Мультфильм.
9.45 Слово пастыря.
10.00 15.00 18.00 Новости.
10.10 Домашняя библиотека.
10.30 "Утренняя почта"
11.05 "Каламбур".
11.40 Смак.
12.00 "Возвращение Третьяковки."
12.25 "Ералаш".
12.45Х/ф"Впервые замужем".
14.25 "Цивилизация".
15.20 Баскетбол.
16.15 В мире животных.
17.15 "Как это было".
18.25 Джентльмен-шоу.
18.55 Х/ф "В зоне особого внимания".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.40 Х/ф "Жандарм в юбке".
23.40 Х/ф"Пули над Бродвеем".

**РОССИЯ**

8.00 Х/ф "Три толстяка"
9.30 "Лабиринт".
9.55 Доброе утро,Страна!
10.45 Кроссворд.
11.15 "Почта РТР".
11.40 "Любовь с первого взгляда"
12.05 Подиум д"Арт.
12.35 "Домашний очаг"
13.00 "Неделя в Санта-Барбаре"
14.00 20.00 Вести.
14.30 "Люди и деньги".
15.00 Федерация.
15.50 "Ваши любимые мелодии".
16.00 Башня.
16.25 Арена.
16.55 Футбол.
18.55 Моя семья.
20.35 Комедия"Игра на миллионы".
22.25 Музыкальный ринг.
23.55 Адамово яблоко.
0.20 Кольцевые автогонки
0.40"Любовные грезы Эдгара М".

**РИО**

7.05 Дорожный патруль.
7.20 ДИСК-канал.
8.05 14.25 Мультфильмы.
8.30 "Детектив Боги".
8.55 "Солти". Сериал.
10.15 "Прекрасные господа из Буа-Доре". 4 серия
11.05 23.05 0.35 "З.К."
11.30 16.30 23.30 ТСН-6
11.45 "Любовные подвиги Геракла".(США).
13.35 Телемагазин.
13.50 "Нью-Йорк","Нью-Йорк".
15.00 Телемагазин.
15.05 Концерт.
16.10 23.35 "Такси ТВ-6"
16.20 Видеоклипы.
16.40 ДИСК-канал.
17.35 Дорожный патруль.
17.50 Док.фильм.
18.55 "Звезды о звездах".
19.25 Видеоклипы.
19.40 "О.С.П. - студия".
20.30 Скандалы недели.
21.05 "Фитиль".
21.20 "Жестокий романс".
0.05"Шоу Бенни Хилла".
1.00 ТСН-6.
1.10 "Такси ТВ-6".
1.25 "Тонго".Боевик.

## ВОСКРЕСЕНЬЕ

### 2 АВГУСТА

**«ТАТАРСТАН»**

7.00 - 8.00 "Чулпан"
17.45 "У зеленого камина"
18.30 "Видеоспорт"
18.45 "Телебуклет"
19.00 "ТОН"
19.40"Автокалейдоскоп "
20.00"Ханым"
20.30"Әлли-бәлли - бәү"
20.45 "Бер алманы бишкә бүләек"
21.30 Ф.Бүләков. "Ах, Бибинур, Бибинур"

**ОРТ**

8.00 Х/ф "Ах,водевиль, водевиль...".
9.15 Лотто-Миллион.
9.30,16.40"Дисней-клуб"
10.00,15.00,1.20 Новости
10.10"Непутевые заметки" Дм.Крылова.
10.30 Пока все дома.
11.10 Утренняя звезда.
12.00 Армейский магазин
12.30 "Играй, гармонь любимая!"
13.00 Крестьянские ведомости.
13.30 "Подводная одиссея команды Кусто".
14.25 Смехопанорама.
15.20 Клуб путешественников.
16.05 Футбольное обозрение.
17.35 "Колесо истории".
18.20 "Женские истории"
18.55 "Ералаш".
19.20"Ответный ход"Х/ф
21.00 Время.
21.35 Х/ф "Леопард".
0.40 Баскетбол.

**РОССИЯ**

8.00 Красная книга.
8.30 "Служу Отечеству!".
8.55 Утро крестьянина.
9.25 Вовремя.
9.55 Доброе утро, Страна!
9.45 Сам себе режиссер.
11.15 Русское лото.
11.55 "Аншлаг"и Ко.
12.45 "Мир книг с Леонидом Куравлевым".
13.00 "Неделя в Санта-Барбаре".
14.00 20.00 Вести.
14.30 Концерт.
15.55 "Закон и порядок"
16.50 Диалоги о животных
17.50 Совершенно секретно.
18.45 Старая квартира.
20.35 Х/ф "Кольцо".
22.25 К-2 представляет.
23.10 Мелодрама"Лето любви".

**РИО**

7.05 Дорожный патруль.
7.15 ДИСК-канал.
8.00 Мультфильм.
8.20 "Детектив Боги"
8.55 "Солти".Сериал.
9.45 "Прекрасные господа из Буа-Доре".
10.55 Шоу еды.
11.30 17.30 ТСН-6.
11.45 "Три ниндзя".Х/ф.
13.35 Телемагазин.
13.45 16.10 Видеоклипы.
13.55 "Канон".
14.30 "Я сама".
15.30 Док.сериал.
15.55 22.50 Такси ТВ-6.
16.15 Телемагазин.
16.20 Спорт недели.
17.00 "Назло рекордам".
17.40 Дорожный патруль
17.50 Док.фильм.
19.00 Обозреватель.
20.00 "Фитиль".
20.20"Год дракона".США
22.55 "Шоу Бенни Хилла"
23.45 Фильм-концерт.
0.15 Ночной сеанс.

***Экспресс-центр*** Экспресс-центр*** Экспресс-центр*** Экспресс-центр***

*● Сәфәрдән кайткач*

## ХУҖАЛАР ТАВЫНДА

Бер җомга көнне "Татарстан" КХАсы сыер савучылары автобуска утырып изге сәфәргә юл тоттылар. Көн кояшлы, гаҗәеп матур, ачык тәрәзәдән искән җил битләрне сыйпый. Басудагы тургайлар да бүген матуррак, моңлырак сайрыйдыр кебек.

Менә без изге Хуҗалар Тавына килеп җиттек: Халыкның күп җыелуы сабан туен хәтерләтә. Килеп төшүгә үзеңне әкияттәгедәй хис итәсең. Искиткеч матур, ямьле бу җир. Һәркайда чисталык, пөхтәлек, тулы тәртип хөкем сөрә. Ник бер чебен-черки күренсен, әйтерсең лә, изге җирдә андый бөҗәкләр очарга тиеш түгел. Түбәләре буялган ашау урыннары. Бер кырыйда бирәдәге изге йола - корбан чалу урыны. Корбан чалуның да шаһиты булдык.

Менә без әкрен генә озын баскычлар буйлап изге тау башына менәбез, эскәмияләргә утырып ял итәбез һәм тирә - юньне күзәтәбез. Баскыч буйлап үсеп утырган агач ботакларына төрле кулъяулыклар бәйләнгән, араларында бик күптәнгеләре дә бар. Тауга менеп җитәрәк "Кызлар каберлеге". Бирәдә изге сугышта һәлак булган кырык кызны җирләгәннәр, диләр.

Ниһаять, без тау башында. Анда бер чал чәчле бабай үзенең изге догаларын укый. Һәйкәл сыман мәгърур булып өч биек таш басып тора. Аста чуер ташлар.Изге ташлар... Кулларыбыз белән сыйпый - сыйпый, без ташлар тирәли әйләнәбез. Эчтән белгән догаларыбызны укып, изге теләкләребезне әйтәбез.

Тау башыннан төшүгә чишмә. Изге чишмә ага да ага. Мин чишмә янына киләм. Изге суны иреннәремә тидерәм, битемне чылатам. Шундый саф, чиста, шундый йомшак бу су! Аны эчкән саен тәнгә сихәтлек, рәхәт тойгы тарала. Чишмә төбенә сәдака акчалары сибәм. "И, ходай, исәнлек бир син безгә" - дип пышылдыйм.

Барыбыз да аш урынына җыелып түгәрәк өстәл тирәли утырышабыз. Өстәл уртасында табынга ямь биреп самавыр җырлап утыра. Итле шулпа ашап, тәмле чәйләр эчеп, ял иткәч дога кылып, урыннарыбыздан кузгалабыз. Җаннарыбызга рухи ял алып, якты уйлар белән кайтыр юлга чыгабыз.

Изге суларны үзебез белән дә алдык. Күңелгә кереп калган якты истәлекле көнне хәтердән тиз генә җуясы килми.

**З.ИСМӘГЫЙЛОВА.**
**Кычытканлы авылы.**

***Роза САФИНА***

## ӘНИ ЕЛЫЙ...

*Әни елый. Нинди кайгысы бар*
*Моңнар белән аккан күз яшендә?*
*Кайгыданмы, әллә шатлыктанмы*
*Никтер базмый әни эндәшергә.*
*Әни елый... Мин юатам аны:*
*Вакыт үткәч, дөнья үзгәрә.*
*Шамакайлар күреп шатланмасын,*
*Кирәк, әни, кирәк түзәргә.*
*Замананың буа кара кулы,*
*Тирә - юньдә бик күп аның колы.*
*Тыштан ялтырыйлар кайберәүләр,*
*Тик эчләре генә кара тулы.*
*Чәчләреңә төшкән ап - ак кырау.*
*Үз - үзеңә бир син, әни, сорау:*
*Узган еллар бәхет китергәнме,*
*Үтелмәгән юллар үтелгәнме?*
*Битләремә куеп - куеп үбәм*
*Сөялләнеп беткән кулларыңны.*
*Шул кулларың белән сөеп - назлап*
*Үстергәнсең сылу кызларыңны.*
*Баш өстенә чөеп, кызлар кебек·*
*Бәйлә, әни, ап - ак яулыгыңны.*
*Усал еллар кара сөлек сыман*
*Суырмасын иде саулыгыңны.*
*Бирешергә һич ярамый, әни,*
*Исән булып тигез гомер ит.*
*Авырлыклар килсә, таянырга*
*Балаларың - таянычың бит.*
*Ышан ,әни, картлык көнегездә*
*Ташламабыз сине, әтине.*
*Бурычлыбыз сезгә, ул бурычны*
*Без түләргә тиеш бит инде.*
*Әни елый. Тик шатлыктан елый,*
*Әни күңеле - язгы гөрләвек.*
*Син агымны туктатырмын димә,*
*Актарылып чыкса бер бәреп.*

***

## БЕЗНЕҢ УЙЛАР

*Әгәр синнән сорасалар:*
*Иске дустың кая,-диеп.*
*Белмим, диеп әйтерсең син,*
*Кайчандыр без бергә идек.*
*Әгәр миннән сорасалар:*
*Иске дустың кая, - диеп.*
*Йөрәгемдә, диярмен мин,*
*Яшим аны әле дә сөеп.*



***Абагалар үскән карурманда***
***Төннәрендә Сак - Сок очкандыр.***
***Мең төрле сер шунда яшеренеп,***
***Тылсым көче шунда поскандыр.***
***Уйларыма чумып атлаганда***
***Өннәремдә күрдем, йа алла:***
***Язмышларга үчле булды микән -***
***Ап - ак чәчәк аткан абага!***

***Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ фотоэтюды.***

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Югары Нурлат авылында яшәүче
**Румия Хаҗиәхмәт кызы Мөхәммәтовага**
50 яшь тула.

Кадерле әниебез! Без сине туган көнең белән чын күңелдән котлыйбыз.
Телибез сиңа исәнлек, изге теләк,
Яшә рәхәт, күрмә кайгы - хәсрәт.
Бәхетле һәм якты булсын
Синең тормыш, синең киләчәк.

**Кызларың, киявең, оныкларың.**

*Бездә ничектер - аларда шулай*

## ӨЙДӘ ЯШЬ КЫЗ БУЛСА, ТӘРӘЗЕН ЧӘЧӘК БИЗӘР

Төркиядә чәчәкләр бик күп үсә, шуңа күрә аны "Гөлләр иле" дип тә йөртәләр. Бирәдә чәчәкләр, гөлләр белән бәйле бик күп кенә традицияләр һәм йолалар бар.

Изниктә хәзерге көнгә кадәр роза гөле үстерү буенча ярышлар үткәрелә. Чәчәкләрнең иң матуры, башкаларыннан аерылып торганы "Ел чәчәге" дигән мактаулы исем ала.



Ыспартада бу көнне иртән - иртүк торып, чәчәк җыярга китәләр. Кайткач, җыйган чәчәкләрдән такыя үрәләр. Кайбер чәчәкләрнең суларын эчәләр, алардан хәтта төрле кайнатмалар (варенье) да ясыйлар.

Халыкта шундый ышану да бар: әгәр җомга көнне берәр чәчәк яисә яран гөле яфрагын башыңа таксаң, баш авыртмас. Ә роза чәчәген иснәсәң, бер ел буена авырмассыз.

Чәчәкләр тәрәзә челтәрендә дә үзенең чагылышларын тапкан. Сөмбел чәчәк атканда тәрәзәләргә шул чәчәк төшерелгән челтәрләр эленә, сөмбел түсендәге киемнәр киелә. Роза чәчәк атканда роза чәчәге төшерелгән челтәрләр эленә һәм аның төсендәге киемнәр киелә.

Анадолуның кайбер төбәкләрендә кияүгә китмәгән яшь кызлар яшәгән өйләрдә урам ягыннан күренеп торырлык итеп тәрәзә төпләренә гөл тезәләр. Бу гөлләрне күреп, кыз сорарга дип, өйгә кияү килә.

Кыз кияүгә чыкканда бирнәсендә чәчәк савытлары күп була. Кияү йортының капкасына эленгән туй байрагына чәчәк бәйләме дә асалар.

Кыз кияү йортына төшкәндә үз өеннән тамырлы чәчәк яисә берәр агач үсентесе алып китә. Әгәр чәчәк яисә агач сулмыйча үсеп китсә, димәк никах ныклы булачак.

Төрекмәннәр үлгән яшь хатынның учына яңа гына өзелгән чәчәк салып күмәләр.

Чәчәк үстерү белән шөгыльләнүчеләрне һәр җирдә диярлек очратырга мөмкин. Алар үстергән чәчәкләр кешеләрнең күңеленә шатлык өсти, аларны изге эшләргә рухландыра.

## НИЧӘ ЯШЬТӘ ӨЙЛӘНЕРГӘ КИРӘК?

***Өйләнешүче егет белән кызның яшь аермасы күпме булырга тиеш? Бу сорауны бик еш ишетергә туры килә. Гаилә терапевты Арман Самантыаерма кимендә 6 яшь булырга тиеш, дип исәпли. Ул моның сәбәбен хатыннарның ирләргә карата тизрәк картаюы белән аңлата. Егет белән кыз арасындагы картаю нисбәттә 15 - 20 ел үткәч кенә тигезләнә икән. Шуңа күрә дә өйләнешүчеләрдә яшь аермасы булырга тиеш.***

***Тикшеренүчеләр мәгълүматлары буенча Төркиядә гаилә коручыларның яшь кимәле, өлкәләргә бәйле рәвештә, төрлечә була. Мәсәлән, Төркиянең кайбер көньяк районнарында 14 - 15 яшьлек кызларны кияүгә бирәләр. Шәһәрләрдә исә 24 - 25 яшьлек кызлар һәм 29 - 30 яшьлек егетләр картайган булып исәпләнә. Белгечләр моның сәбәбен климат һәм яшәү урыны белән бәйләп аңлаталар. Эссе климатлы төбәкләрдә өйләнешүчеләрнең яше дә кечерәк була. Шуны да әйтергә кирәк: 24 яшьтән узган кызларның, 29 яшьтән узган егетләрнең өйләнү очраклары бик сирәк, чөнки алар турында "өйләнешү вакыты узган" дигән фикер йөри башлый. Соңлап өйләнешү ана булырга теләгән хатын - кызлар өчен дә, бала сәламәтлеге өчен дә куркыныч. Аеруча 35 яшьтән соң сәламәт бала табу ихтималы бик нык кими.***

***("Заман - Татарстан" нан).***


## БЕЛДЕРҮЛӘР.

### САТАБЫЗ

**ВАЗ - 21013.** Адрес: Гоголь ур., 15.

***

**Әфган поселогында эчке эшләре эшләнмәгән верандасы белән 10 x 12 ле яңа кирпеч йорт, участогы әйләндереп алынган, кыйммәт түгел.** Тел.: 2-18-21.

***

**Бер бүлмәле фатир.** Тел.: 4-12-02, кичке 5тән соң.

***

**Цемент, илтеп бирәбез.** Тел.: 2-28-18.

***

**1995 елгы, бик әйбәт хәлдәге 4x4ле ВАЗ - 21213 (биш тизлекле), 1998 елдан кулланылышта, 3мең км. юл үткән.** Тел.: 5-24-96.

***

**1,35 x 6 метрлы профнастил, 25 табак.**
Адрес: Киров ур., 10.

***

**ГИБДД (элеккегэ ДАИ) территориясендә капиталь гараж.**
Тел.: 2-25-61.

***

**Йөреп торган "Москвич - 412", кыйммәт түгел.**
Адрес: Козлов ур., 3-11.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Тимер юл кичүе янында гараж биреп торабыз.**
Адрес: Калинин ур., 50.

***

***Кондырча елгасы ярында Владимир Александрович Афанасьев исеменә бумажник, паспорт, шофер таныклыгы, техпаспорт һ.б. документлар табучының 1 мең сум бүләк бәрабәренә иясенә кайтарып бирүен үтенеп сорыйм.***
Адрес: Кошки авылы, 60 лет Октября ур., 42. Тел.: (код) 8 - 846 - 50 2-12-56, 2-28-34.

***

**Кичке мәктәп тарафыннан Максим Анатольевич Борзов исеменә бирелгән 2914439 номерлы аттестатны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип санарга.**



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр:Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.
Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*ГазетаТатарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2337 данә. 2992